БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

15 декабрь 2022 ел № 161

**Балтач муниципаль районы башлыгының «Иң яхшы сыйныф җитәкчесе» грантын бирүгә конкурс үткәрү тәртибен раслау турында**

Мәгариф оешмалары җитәкчеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрүгә ярдәм итү, мәгариф оешмаларында нәтиҗәле, алдынгы һәм инновацион менеджментны пропагандалау һәм мәгариф оешмалары җитәкчеләренең укыту-административ эшчәнлеген оештыруны ачыклау һәм камилләштерү максатларында, Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Советы **карар бирде:**

1. Балтач муниципаль районы башлыгының «Иң яхшы сыйныф җитәкчесе» грантын бирүгә конкурс үткәрү Тәртибен 1 нче кушымта нгезендә расларга.
2. Балтач муниципаль районы Финанс-бюджет палатасына әлеге максатларга җирле бюджетта каралган ассигнование чикләрендә финанслауны тәкъдим итәргә.
3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет - ресурсында бастырырга һәм baltasi.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р. Р. Нотфуллин

Татарстан Республикасы
Балтач район Советының
2022 елның 15декабрендәге
161 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Балтач муниципаль районы башлыгының**
**«Иң яхшы сыйныф җитәкчесе» грантын бирүгә конкурс үткәрү Тәртибе**

## I. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Балтач муниципаль район башлыгының мәгариф оешмаларының иң яхшы педагогик хезмәткәрләренә грант бирү буенча конкурс үткәрүнең әлеге тәртибе (алга таба-эшчәнлек тәртибе) һөнәри эшчәнлегендәге югары казанышлары өчен 1 урын – 30 000,00 сум, 2 урын -15 000,00 сум, 3 урын – 10 000,00 сум күләмендә акчалата бүләкләү рәвешендә Балтач муниципаль район башлыгының мәгариф оешмаларының иң яхшы педагогик хезмәткәрләренә грант бирү буенча конкурс оештыру һәм үткәрү кагыйдәләрен билгели.

Әлеге түләүләргә карата физик затлар керемнәренә салым (НДФЛ) каралган.

1.2. Әлеге Тәртиптә түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

- конкурс - мәгариф оешмаларының иң яхшы сыйныф җитәкчеләрен акчалата бүләкләүгә конкурс;
- конкурста катнашучы - педагогик эшчәнлек стажы кимендә ике ел булган, төп эш урыны районның белем бирү оешмасы булган сыйныф җитәкчесе;
- вәкаләтле органы - Балтач район башкарма комитеты «Мәгариф идарәсе» МКУ (алга таба - Мәгариф идарәсе);
- рейтинг - әлеге Тәртипнең IV бүлеге нигезендә йомгаклау билгеләре суммасын кимету тәртибендә формалашкан конкурста катнашучылар исемлеге.

1.3. Акчалата бүләкләү хәбәрдарлык, процедураларның ачыклыгы, аңлаешлылыгы һәм мәгариф оешмалары сыйныф җитәкчеләренә катнашу өчен тигез мөмкинлекләр тәэмин итү принципларына нигезләнгән конкурс сайлап алуы нәтиҗәләре буенча гамәлгә ашырыла. Конкурста сайлап алу конкурска кирәкле оештыру, эксперт һәм мәгълүмат белән тәэмин итү ягыннан ярдәм итүче вәкаләтле орган тарафыннан үткәрелә.

1.4 Балтач район Советы карары белән расланган конкурс комиссиясе составына Мәгариф идарәсе, үз эшчәнлеген мәгариф өлкәсендә гамәлгә ашыручы иҗтимагый берләшмәләр белгечләре арасыннан кимендә биш кеше керә.

1.5. Конкурс комиссиясе әгъзалары конкурсантларны конкурс критерийлары нигезендә бәялиләр.

1.6. Конкурста сайлап алуда җиңүче дип конкурсның читтән торып катнашу этабында һәм турыдан-туры катнашу этабында иң күп балл җыйган сыйныф җитәкчесе танyла.

1.7. Конкурста сайлап алу җиңүчесе Район башлыгы Гранты белән бүләкләнә.

1.8. Акчалата бүләкләү алган иң яхшы сыйныф җитәкчеләре өч елдан да иртәрәк булмаган вакытта конкурста кабат катнашырга хокуклы.

## II. КОНКУРСНЫҢ МАКСАТЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

2.1. Конкурсның максаты - район мәгариф оешмаларының сыйныф җитәкчеләренең тәрбия эшчәнлеген стимуллаштыру, аларның иҗади һәм һөнәри потенциалын үстерү.

2.2. Конкурсның бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

- сыйныф җитәкчесенең абруен күтәрү, аның педагогик тәҗрибәсен пропагандалау;
- сыйныф җитәкчесе турында т әрбияче, әхлакый кыйммәтләр йөртүче буларак иҗтимагый фикер формалаштыру.

## III. КОНКУРСТА САЙЛАП АЛУ ҮТКӘРҮ ТӘРТИБЕ

3.1.Сыйныф җитәкчеләрен тәкъдим итү гомуми белем бирү учреждениесе тарафыннан башкарыла.

3.2. Конкурста катнашу өчен материаллар 20 гыйнварга кадәр Балтач район башкарма комитеты «Мәгариф идарәсе» МКУнә түбәндәге адрес буенча җибәрелә: Балтач ш.т.п., Ленин ур., 63.

Аларны рәсмиләштерүгә таләпләрне бозып әзерләнгән, шулай ук оештыру комитетына күрсәтелгән вакыттан соңрак кергән документлар каралмый.

Конкурста катнашу өчен оештыру комитеты адресына ике телдә түбәндәге материаллар тапшырыла:

- Район конкурсында катнашу өчен кандидатуралар тәкъдим итү турында гомуми белем бирү учреждениесенең карар беркетмәсе.
- Сыйныф җитәкчесенең түбәндәге документларны үз эченә алган портфолиосы:

3.2.1 Сыйныф җитәкчесе эшчәнлеген регламентлаучы документлар исемлегенең тәкъдим итү тасвирламасы белән аналитик белешмә:

- квалификация күтәрү курслары (документларның күчермәләре);
- агымдагы уку елына чаралар планнары;
- тәрбия системасы субъектлары белән уртак планнар;

- мәктәптә контрольдә тотылырга тиешле балигъ булмаганнарның аерым категорияләрен исәпкә алу журналы;

3.2.2 Сыйныф җитәкчесенең укучылар белән тәрбия эшенең нәтиҗәлелеге (соңгы ике елда):

Укучылар:

- катнашучылар санын, призлы урыннарны күрсәтеп, сыйныфта укучыларның мәктәп, муниципаль, республика, башка чараларда катнашу нәтиҗәләре; **3 балл**
- авыр тормыш хәлен бетерүгә бәйле рәвештә профилактик исәпкә алынган укучылар саны (чагыштырып), сыйныфта хокук бозулар, җинаятьләр дәрәҗәсе киму (арту) (чагыштырып); **3 балл**
- балигъ булмаганнарның белем өлгереше һәм дәресләргә йөрүе (шул исәптән, профилактик исәптә торучылар); **3 балл**

**Максималь балл 9.**

3.2.3 Дәрестән тыш эшчәнлек (соңгы ике елда).

- сыйныфтан тыш чаралар эшләү: исеме (интернет челтәрендә урнаштырылган ресурска сылтама); **3 балл**
- укучыларның проект эшчәнлеге: гамәлгә ашырылган проектлар исемлеге; **3 балл**
- сыйныф җитәкчесе тарафыннан дәрестән тыш үткәрелгән чаралар саны (исемнәре, уздыру датасы, катнашучылар саны); **3 балл**
- катнашучылар санын күрсәтеп, сыйныфта укучыларның мәктәп, муниципаль, республика, башка чараларда катнашу нәтиҗәләре; **3 балл**
- кызыксынулары буенча түгәрәкләрдә һәм секцияләрдә шөгыльләнүче укучылар саны
(өстәмә белем бирүдә; мәктәптә; мәдәният, спорт учреждениеләрендә); **3 балл**
- сыйныф һәм мәктәп тормышында ата-аналарның катнашуы; **3 балл**
- тәрбия системасы субъектлары белән үзара хезмәттәшлек (субъектлар вәкилләре катнашында гомуми чаралар уздыру); **3 балл**

**Максималь балл 21.**

3.2.4. Заманча белем бирү технологияләрен тәрбия эше барышында куллану:

- тәрбия юнәлешендәге программалар булу, күрсәтмә, дидактик материаллар һ.б.; **1 балл**
- тәрбия эше барышында мәгълүмат-коммуникация технологияләрен куллану; **1 балл**

**Максималь балл 2.**

3.2.5. Һөнәри эшчәнлектә катнашу, уңышлар (соңгы ике елда).

- муниципаль, республика, Россия (халыкара) чараларында (конкурсларда, семинарларда, конференцияләрдә һ.б.) катнашу нәтиҗәләре; **3 балл**
- фәнни-методик басмалар (сылтама). **3 балл**

**Максималь балл 6.**

3.2.6 Үз педагогик тәҗрибәсен гомумиләштерү һәм тарату (соңгы ике елда).

- педсоветларда, конференцияләрдә, семинарларда, мастер-классларда, «түгәрәк өстәлләрдә» һ.б. чыгышлар тематикасы; **3 балл**
- чыгышлар материаллары; **3 балл**
- дәрәҗәсен күрсәтеп, басылып чыккан хезмәтләр (публикацияләр) исемлеге; **3 балл**
- сыйныф җитәкчесе ихтыяры буенча башка материаллар. **3 балл**

**Максималь балл 12.**

Документлар исемлек нигезендә бирелә һәм кәгазь чыганакларда рәсмиләштерелә. Шрифт Times New Roman, Шрифт размеры № 12, арадаш интервал 1,5.

1.2-1.6 пунктлары өчен сыйныфта укучылар саны 0,1 коэффициенты белән исәпкә алыначак.

**Читтән торып катнашу этабы нәтиҗәләре буенча турыдан-туры катнашу этабына катнашучылар рейтингы төзелә.**

**Конкурсның II этабы - турыдан туры катнашу**

Конкурсның турыдан-туры катнашу этабы ярышлары «Кеше тәрбияләү» тәрбия юнәлешендәге хезмәткәрләрнең һөнәри осталыгы республика конкурсының нигезләмәсе нигезендә уздырыла.

## IV. АКЧАЛАТА БҮЛӘКЛӘҮ БИРҮ ТӘРТИБЕ

4.1. Конкурсның ике этабында иң күп балл җыйган педагог конкурсның җиңүчесе була. Конкурс нәтиҗәләре буенча Балтач район башлыгының боерыгы раслана, аның нигезендә акчалата бүләкләү түләнә.

Акчалата бүләкләү өчен түбәндәге документлар кирәк:

- акчалата бүләкләү турында шәхси гариза;
- шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык;
- акчаларны күчерү өчен счет реквизитлары;
- шәхесне таныклый торган документның күчермәсе.